ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 декабрь, 2015 ел № 5/6

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар хакында

Гражданнарның һәм физик затларның мәнфәгатьләренә кагылышлы җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру һәм шәһәр территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу тәртибен камилләштерү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 маддәсе, Россия Федерациясе Җир кодексының 84 маддәсе, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 19 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын (алга таба – Шәһәр Советы карары проекты) халык яши торган пункт чикләрен үзгәртү һәм халык яши торган пункт җирләреннән сәнәгать территорияләрен чыгару өлешендә 1 нче кушымтадагыча хупларга һәм гавами тыңлауларда карап тикшерүгә куярга.
2. Шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү көнен 2016 елның 11 февраленә тәгаенләргә, үткәрү вакытын 14.00 сәгатькә, гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасын (Х.Туфан проспекты, 23 йорт), 400 залны билгеләргә.
3. Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү буенча гавами тыңлаулар үткәрү комиссиясенә әлеге карарның һәм Шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында хәбәрнең «Челнинские известия» газетасында басылып чыгуын һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырылуны тәэмин итәргә.

4. Шәһәр Советының 2006 елның 10 февралендәге «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар турында» 8/26 санлы Карары (Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге 33/15, 2015 елның 17 июнендәге 40/10 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.1 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия составы Башкарма комитет тарафыннан расланa.»;

2) 2.2 пунктының өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

5. Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар турында» 33/15 санлы Карарының 4 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһр Советының
5/6 нчы Карарына
кушымта
28 декабрь, 2015 ел

Проект

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Шәһәр Советы

К А Р А Р

, 2016 ел №

Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына
үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап тикшергәч, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 маддәсе, Россия Федерациясе Җир кодексының 84 маддәсе, 1998 елның 24 июнендәге «Житештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 19 маддәсе нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2006 елның 27 июнендәге 14/4 санлы Карары (Шәһәр Советының 2014 елның 9 декабрендәге 35/11 санлы Карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре Генераль планы сызымында, торак пункт җирләреннән территорияләрне чыгарып, торак пункт чикләренә кушымтадагыча үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советы Карарына
кушымта
_______________, 2016 ел

# ЧЕРТЕЖ ГЕНЕРАЛЬНОГО ПЛАНА ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ

